ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КҮЛЛЕ-КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

КУЛЛЕ-КИМИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422742 Республика Татарстан Атнинский район с. Кулле-Кими ул.Кирова 1А Тел. 3-53-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «02» октября 2024 г. № 5

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Бахтачы торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2024 елнын 21 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенә керүче Бахтачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бахтачы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2024 елның 21 ноябре 13.00 сәгатькә;

-үткәрү урыны – Бахтачы авылы, Совет урамы,29А йорты;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 14 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;

- сайлау хокукына ия булган Бахтачы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

-гражданнар җыены турында Бахтачы торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2025 елда Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Бахтачы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, Бахтачы

авылына юлны ремонтлау, вак таш сатып алу һәм салу, эш һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү)

2) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, мотопомпа сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)»

“РИЗА” “КАРШЫ”

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күлле-Киме авылы, Киров урамы 1А йорты адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.
3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Х.Х.